КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 апрель г.Казань № 208

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 157 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 961 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның дүртенче абзацында «эшкә яраклы яшьтәге (60 яшькәчә ир-ат, 55 яшькәчә хатын-кыз)» сүзләрен «60 яшькәчә» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кандидатта һәм аның гаилә әгъзаларында алынмаган яки капланмаган суд хөкеме булмау турында белешмә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин